СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.07.2019 Баулы шәһәре № 216

Баулы муниципаль районы Советының
2018 елның 13 декабрендә кабул ителгән
183нче номерлы «Баулы муниципаль
районының 2019 елга һәм 2020 һәм
2021 еллар план чорына бюджеты
турында» карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә таянып, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 13 декабрендә кабул ителгән 183нче номерлы «Баулы муниципаль районының 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына бюджеты турында» карарына (Баулы муниципаль районы Советының 2019 елның 4 февралендәге 193нче, 2019 елның 27 мартындагы 199нчы, 2019 елның 20 майның 212нче, 2019 елның 5 июннең 214нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 статьяның 1 пунктындагы 1, 2, 3 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Баулы муниципаль районы бюджетының фаразланган гомуми кереме күләме 870756,2 мең сум;

2) Баулы муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1001828,2 мең сум;

3) Баулы муниципаль районы бюджеты дефициты 131072 мең сум күләмендә.».

2. 4нче кушымтаны түбәндәге юллар белән тулыландырырга:

| | | |
|---|---|---|
| 803 | 2 02 30027 05 0000 150 | Баланы опекун гаиләсендә һәм тәрбиягә алган гаиләдә карап тотуга, шулай ук тәрбиягә бала алган ата-ананы бүләкләүгә муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр |
| 803 | 2 02 45453 05 0000 150 | Виртуаль концерт залларын булдыруга муниципаль районнар бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |
| 803 | 2 02 45454 05 0000 150 | Муниципаль модель китапханәләр булдыруга муниципаль районнар бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |

1, 2, 5, 6 номерлы кушымталардагы 1нче таблицаларнына 1, 2, 6, 7, 13нче кушымталар нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
Район Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин